| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 05 2025 ел № 154

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүче гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

Демографик вәзгыятьне яхшырту һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында халык саны кимүнең тискәре тенденцияләрен бетерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүче Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган 25000,00 (егерме биш мең) сум күләмендәге өстәмә социаль ярдәм чарасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүче Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән гражданнарга, бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына җирле бюджет акчаларыннан әлеге карарда күрсәтелгән өстәмә социаль ярдәм чарасын финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җитәкче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 елның "15" 05
154 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүче Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибе.

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүче Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр акчалата түләү бирү механизмын билгели (алга таба - бер тапкыр түләү)

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүче гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган 25000,00 (егерме биш мең) сум күләмендәге акчалата түләү түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

- бала туу Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының ГХАТ бүлегендә теркәлергә тиеш;

- бала Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча теркәлергә тиеш.

3. Күп балалы йөклелек булганда, бер тапкыр бирелә торган түләү һәр балага бирелә.

Бала үле туган очракта түләү башкарылмый.

Хатын-кыз вафат булганда, ул ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән (ата-ана хокуклары чикләнгән) очракта, бала туу уңаеннан бер мәртәбә түләү баланың атасына (опекунына) бирелә.

4. Бала туу уңаеннан бер мәртәбә түләү балалары тулысынча дәүләт тәэминатында булган гражданнарга, шулай ук ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокукларыннан чикләнгән гражданнарга билгеләнми.

5. Бер тапкыр бирелә торган түләүне алу өчен кирәкле документлар исемлеге:

- бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза (алга таба - гариза);
- әлеге тәртипкә кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
- ата-ананың берсенең паспортыннан теркәү битләре күчермәсе;
- акчаны күчерү өчен банк реквизитлары;
- 14 яшькә кадәрге балаларның теркәлүен раслый торган документ (яшәү урыны буенча теркәлү турында 8 номерлы формадагы таныклык)
- бала туу турында таныклык күчермәсе.

6. Бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү өчен законлы вәкил (мөрәҗәгать итүче) Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының ГХАТ бүлегенә (алга таба - вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшыра:

- бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза (алга таба - гариза),
- әлеге тәртипкә кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
- ата-ананың берсенең паспортыннан теркәү битләре күчермәсе.
- акчаларны күчерү өчен банк реквизитлары.

6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар:

- 14 яшькә кадәрге балаларның теркәлүен раслый торган документ (яшәү урыны буенча теркәлү турында 8 номерлы формадагы таныклык)
- бала туу турында таныклык күчермәсе.

6.2. Вәкаләтле орган тарафыннан 30 календарь көн эчендә 2.1 пунктында

күрсәтелгән документлар гомумиләштерелә һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына карар кабул итү өчен җибәрелә.

7. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты 5 эш көне эчендә бер тапкыр акчалата түләү бирү/бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм күрсәтмә акты чыгара.

8. Мөрәҗәгать итүчеләрнең кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү суммасын күчерү бу хакта карар кабул ителгән көннән башлап утыз эш көне эчендә башкарыла.

9. Тапшырылган мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә аны алуга хокук булмауның ачыклануы бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләүдән баш тарту өчен сәбәп булып тора.

10. Берьюлы бердән артык бала туган очракта, акчалата түләү һәр туган балага бирелә.

Форма

20_____ елның "___"___________" _____ номерлы

ГАРИЗА

Мин __________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

| Шәхесне раслый торган документның исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча теркәлгән : __________________________________

________________________________________________________________________

____________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индекс, телефон номеры, электрон почта адресы күрсәтелеп)

СНИЛС (мөрәҗәгать итүченең) ______________________________.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 20__елның"___"___________"_____номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бала туупы теркәгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәүчегә бала (балалар) туганда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләүне сорыйм,

______________________________________________________________;

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), туу датасы)

______________________________________________________________;

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), туу датасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән социаль ярдәм чаралары күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга ризамын

______________________________________________________________

(почта адресына, электрон почта аша күрсәтелгән электрон адреска хат формасында)

Дата_________________ __________________________________________

(гариза бирүче имзасы)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________

(Ф.И.О. тулысынча (соңгысы – булган очракта))

_____________________________________________________________________

(контакт мәгълүматы: телефон номеры, электрон почта адресы яисә шәхси мәгълүматлар субъектының почта адресы)

бала (балалар) тугач бер тапкыр акчалата түләү билгеләү максатларында, минем һәм минем балигъ булмаган балаларымның шәхси белешмәләрен (белешмәләрне) һәм шәхси мәгълүматларын автоматлаштыру чараларын кулланып яисә алардан башка жыюны, язу, системалаштыру, туплауны, саклау, төгәлләштерүне (янарту, үзгәртү), мәгълүмат алу, куллану, тапшыруны (тарату,тәкъдим итү, рөхсәт бирү), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, чикләү, юк итү, юкка чыгаруны)

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(Ф.И.О. (соңгысы - булган очракта), туу датасы)

_____________________________________________________________________

фамилиясен, исемен, атасының исемен; туу датасын; гаилә хәлен; паспорт мәгълүматларын; теркәлү һәм яшәү адресын; контактлы телефон номерын кертеп, эшкәртүгә ризалык бирәм.

Шәхси мәгълүматларны, балигъ булмаган балалар турындагы белешмәләрне эшкәртүгә ризалык, социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен документлар саклауның архив законнарында билгеләнгән вакыты узганчы гамәлдә була.

_____________________________________________________________________

(дата) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (соңгысы - булган очракта) (имза)